**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«04» март 2026 ел Яңа поселогы № 5

«2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге турында» программаны раслау хакында»

2026-2028 елларга Россия Федерациясендә юл хәрәкәте иминлеге стратегиясен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 8 январендәге 1-р номерлы күрсәтмәсен гамәлгә ашыру максатында, Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасын расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әҗмәкәй авыл җирлегенең 2025 елның 31 гыйнарындагы 1 номерлы карары (барлык үзгәрешләре белән) үз көчен югалткан дип санарга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе Г.Т.Хөсәинова

Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитетының

**«2026-2028 елларга
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» ПРОГРАММАСЫ**

**ТР, Тукай районы
2026 ел**

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге» программасы |
| Программаны эшләү өчен нигез | 2018-2024 елларга Россия Федерациясендә юл хәрәкәте иминлеге стратегиясен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 8 гыйнварендәге 1-р номерлы күрсәтмәсе, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 06 декабрендәге 1115-ПУ номерлы Указы, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кыскарту һәм аларның нәтиҗәләрен киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 18 февралендәге 159 номерлы карары |
| Программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге башкарма комитеты |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Программаның максаты – юл-транспорт һәлакәтләренең авырлыгын киметү, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге юлларында аларның законлы хокукларын һәм имин хәрәкәт шартларын тәэмин итү. Максатка ирешү шарты булып түбәндәге бурычларны хәл итү тора:<br>- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегенең юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча дәүләт системасын камилләштерү;<br>- транспорт чараларын йөртүчеләрне һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү сыйфатын күтәрү;<br>- юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү һәм транспорт чараларын йөртүчеләрнең ышанычлылыгын арттыру;<br>- юл хәрәкәте иминлеген пропагандалауның, контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;<br>- транспорт чараларының конструктив һәм эксплуатацион куркынычсызлыгына, аларны тормышка ашыру механизмнарына кагылышлы таләпләрне камилләштерү;<br>- юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәле схемаларын, методларын һәм чараларын эшләү һәм куллану;<br>- авыл җирлеге юлларында куркыныч участокларны бетерү һәм булдырмау;<br>- балаларны гына түгел, өлкән яшьтәге кешеләрне дә (шул исәптән пенсионерларны) урамда һәм юлларда хәрәкәт итү куркынычсызлыгы кагыйдәләренә өйрәтү системасын камилләштерү;<br>- авария-коткару эшләренең һәм юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2026-2028 еллар |
| Тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләр | Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә авариянең индикатив күрсәткечләре киму көтелә: юл-транспорт һәлакәтләренең авырлыгы.<br>Юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу очраклары ачыклану дәрәҗәсен республика буенча уртача күрсәткечтән |

| | |
|---|---|
| | югарырак күтәрергә, шул ук вакытта ЮХИДИ бүлекчәсе эшчәнлеген тизлекне арттыру, узып китү, юл чатында йөрү кагыйдәләрен үтмәү кебек бозуларны ачыклауга юнәлдерергә, бу юл-транспорт һәлакәтләренең кимүенә сизелерлек йогынты ясаячак.<br>Авыл җирлеге территориясендә һәм ТР Тукай муниципаль районы юлларында автомобиль транспорты өлкәсендә авариялелек дәрәҗәсенең кимүе |
| Программаның төп чаралары | Муниципаль дәрәҗәдә юл хәрәкәте иминлеге белән идарә итү структураларын камилләштерү, Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеге идарәсе дәүләт системасының хокукый һәм мәгълүмат базасын камилләштерү.<br>Юл хәрәкәте иминлеге проблемалары буенча максатчан мәгълүмати-пропаганда кампанияләре үткәрү, массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте иминлеге мәсьәләләрен даими яктырту.<br>Балалар һәм яшүсмерләрнең транспорт культурасын тәрбияләү һәм куркынычсыз тәртипкә өйрәтүнең яңа формаларын һәм ысулларын эшләү һәм гамәлгә кертү, автотранспорт профилендәге спорт картинг-клублары, балалар яшүсмерләр автомәктәбе челтәрен булдыру.<br>Машина йөртүчеләрне әзерләү системасын камилләштерү, автотранспорт чараларын йөртүчеләрнең һөнәри осталыгын күтәрү һәм әзерләү буенча алдынгы технологияләр үзәген булдыру.<br>Контроль-күзәтчелек органнарының үзара хезмәттәшлеге системасын камилләштерү, тиз йөрешле хәрәкәт режимын контрольдә тоту өчен техник чаралар һәм җиһазлар кертү, техник карау чараларын гамәлгә кертү |
| Программаның ярдәмче программалары һәм төп чаралары үтәлешен оештыру өчен җаваплылар | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Башкарма комитеты |
| Финанслау күләме һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме 300 мең сум тәшкил итә |

## 1. КЕРЕШ

Әлеге программа «2018-2024 елларга Россия Федерациясендә юл хәрәкәте иминлеге стратегиясен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 8 гыйнварендәге 1-р номерлы күрсәтмәсе, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 06 декабрендәге 1115-ПУ номерлы Указы, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кыскарту һәм аларның нәтиҗәләрен киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 18 февралендәге 159 номерлы карары нигезендә эшләнде.

Әлеге Программа юл-транспорт һәлакәтләренең авырлыгын киметү, гражданнарның гомерен, сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, ТР Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге юлларында аларның законлы хокуклары гарантияләрен арттыру максатларында эшләнде.

Әлеге Программа түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү һәм транспорт чараларын йөртүчеләрнең ышанычлылыгын арттыру;

- юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәле схемаларын, методларын һәм чараларын эшләү һәм куллану;

- җирле юлларда куркыныч участокларны бетерү һәм булдырмау;

- авария-коткару эшләренең һәм юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру.

1. Юл-транспорт һәлакәтләренең төп сәбәпләре булып тора:

- юл хәрәкәтендә катнашучыларның юл хәрәкәте кагыйдәләрен һәм һава-метереологик шартларны үтәмәве;

- машина йөртүчеләрне әзерләү процессы белән төгәл, бердәм идарә итү булмау аларның әзерлек дәрәҗәсенә һәм сыйфатына карата оптималь таләпләр тәэмин итми;

- машина йөртүчеләрне әзерләү сыйфатына һәм юл хәрәкәтендә башка катнашучыларның юлларда үз-үзләрен тотышы культурасына карата таләпләрне арттыру укыту һәм тәрбияләү структурасында, формаларында һәм ысулларында адекват үзгәрешләр белән, мәгариф учреждениеләренең төп массасы педагогик кадрлар составын яхшырту белән бергә алып барылмый;

- халыкның юлларда үз-үзеңне тоту культурасының үзгәрүче юл хәрәкәте шартларына туры килмәве;

- машина йөртүчеләрнең хезмәт һәм ял режимнарын үтәүне контрольдә тотуны камилләштерү;

- юлларның сыйфаты канәгатьләнерлек булмау.

Җәмәгатьчелек фикерен сораштыру нәтиҗәләре күрсәткәнчә, авариялелек торышына хокукый нигилизм һәм куркынычсызлык таләпләренә битарафлык күрсәтү төп йогынты ясый. Сораштырылган шәхси транспорт йөртүчеләрнең якынча 30%ы үз гамәлләрен юл хәрәкәтендә катнашучыларның башка мәнфәгатьләренә туры китерми, 40%ы гадәт буенча юл хәрәкәте кагыйдәләрен боза, чөнки юлда беркайчан тәртип сакламый, 35%ы юл ситуациясе (юлның начар торышы, хәрәкәтне оештырудагы җитешсезлекләр, транспорт агымының югары тыгызлыгы һәм интенсивлыгы) юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозарга мәҗбүр иткән, дип саный, 13%ы юл хәлен кисәтү һәм 5%ы машина йөртүченең игътибары читкә юнәлү дип раслый. Сораштырылучыларның 28%ы кайчан да булса исерек хәлдә транспорт белән идарә иткән, аларның 25%ы, транспорт руле артына утырганда, сизмәсләр һәм җәзага тартылмаслар дип өметләнгән, 20%ы машина йөртү сыйфатына һәм юл хәлен бәяләүгә алкоголь йогынты ясамаячак, дип санаган.

Моннан тыш, җәмәгатьчелек фикерен сораштыру бүгенге көндә машина йөртүчеләр һәм җәяүлеләр арасында үзара мөнәсәбәтләр бик киеренке булуын күрсәтә. Юл хәрәкәтендә катнашучы бу төркемнәрнең үзара каршы торуы, кагыйдә буларак, юлларда куркыныч хәл тудыруга һәм әлеге төркемнәр арасындагы юл-транспорт һәлакәтләренең шактый өлешендә үлемгә китерә.

Җәяүлеләр тарафыннан җәрәхәтләнүгә китергән юл хәрәкәте кагыйдәләрен төп бозулар булып машина йөргән җирдә билгеләнмәгән урында юл аша чыгу, көйләү сигналлары таләпләрен бозу, җәяүлеләрнең юлның машина йөрү өлешендә исерек хәлдә булуы тора. Җәяүлеләр кичүе булмаган урыннарда юлларны чыгу – иң зур куркыныч. Җәяүлеләрнең юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуның объектив сәбәпләре:

- җәяүлеләр кичүләренең җитәрлек булмавы;

- төзекләндерелгән тукталыш мәйданчыклары булмау;

- җәмәгать транспорты тукталу урыннарында «Автобус тукталышы урыны» юл билгеләре булмау;

- юл чатлары зонасында «Главная дорога», «Уступите дорогу» юл билгеләре булмау.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү проблемасы халыкның иң киң катламнары, җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алмыйча хәл итеп булмый. Социаль-психологик системалар, шул исәптән дини укулар, төрле рухи концепцияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр нигезендә халыкның киң массаларының үз-үзләрен тотышы формаларын

һәм иҗтимагый аңын формалаштыру тәҗрибәсе кешеләрнең үз-үзләрен тотышы хакында массакүләм үзгәрешләргә исәп тотарга мөмкинлек бирә. Социаль-психологик системалар, шул исәптән дини укулар, төрле рухи концепцияләр һәм иҗтимагый берләшмәләр нигезендә халыкның киң массаларының үз-үзләрен тотышы формаларын һәм иҗтимагый аңын формалаштыру тәҗрибәсе кешеләрнең үз-үзләрен тотышы хакында массакүләм үзгәрешләргә исәп тотарга мөмкинлек бирә.

Халык белән пропаганда-аңлату эшләре, балалардан башлап, даими алып барылырга тиеш һәм барыннан да элек юл хәрәкәтендәге вакыйгаларның тискәре нәтиҗәләренә бәйле потенциаль куркынычны аңлауга, юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә нормаларны, кагыйдәләрне һәм стандартларны бозучыларга карата тискәре мөнәсәбәт формалаштыруга юнәлтелгән булырга тиеш. Моннан чыгып, юл хәрәкәтендә кешеләрнең хокукый тәртибен формалаштыру юнәлешләрен билгеләгәндә, халыкның төрле социаль һәм яшь категорияләренә юнәлдерелгән дифференциацияләнгән пропаганда үткәрелергә тиеш.

Аварияләлек дәрәҗәсен, китерелгән кеше һәм матди югалтуларны бары тик дәүләт һәм иҗтимагый оешмалар тарафыннан бөтен халыкның актив ярдәме белән законнар чыгару, икътисадый, техник һәм тәрбия характерындагы чаралар комплексын гамәлгә ашырганда гына киметергә мөмкин.

Юл хәрәкәтендә катнашучылар белән эшләүдә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча юлларда халыкның үз-үзен тотышы культурасын күтәрүгә юнәлдерелгән проектны тормышка ашыру Әҗмәкәй авыл җирлегендә аварияләлек дәрәҗәсен киметергә мөмкинлек бирәчәк, бу юл-транспорт һәлакәтләреннән килгән зыянны каплауга матди чыгымнарны киметәчәк.

## 2. ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Программаның максаты булып гражданнарның сәламәтлеген һәм аларның мөлкәтен саклауны тәэмин итү, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге юллары буенча имин хәрәкәт итү шартларына аларның законлы хокукларын гарантияләү тора. Максатка ирешү шарты булып түбәндәге бурычларны хәл итү тора:

- җирлектә юл хәрәкәте иминлеге дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген арттыру;
- юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү һәм транспорт чараларын йөртүчеләрнең ышанычлылыгын арттыру;
- юл хәрәкәтен оештыруның нәтиҗәле схемаларын, методларын һәм чараларын эшләү һәм куллану;
- авыл җирлеге юлларында куркыныч участокларны бетерү һәм булдырмау;
- авария-коткару эшләренең һәм юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүнең нәтиҗәлелеген арттыру.

## 3. ПРОГРАММАНЫҢ ТӨП ЧАРАЛАРЫ. ПРОГРАММА ЧАРАЛАРЫНЫҢ (БҮЛЕКЛӘРНЕҢ) СИСТЕМАСЫ

Программаның максатына 5 максатчан проект белән тәкъдим ителгән программа чаралары комплексын тормышка ашыру нигезендә ирешү күздә тотыла:

<u>1 проект. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү белән идарә итүнең муниципаль системасын камилләштерү</u>

Проектның төп максаты булып Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте иминлеге дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген арттыру тора.

Чаралар планында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү белән идарә итү системасын алга таба камилләштерү каралган. Бу бурыч хәзерге вакытта аеруча актуаль. Әлеге проект кысаларында җирлек дәрәҗәсендә идарә структураларын камилләштерү, юл хәрәкәте

иминлеге белән идарә итүнең дәүләт системасын хокукый һәм мәгълүмати тәэмин итү буенча чаралар комплексын (түбәндә китерелгән) тормышка ашыру күздә тотыла.

Юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм оештыруга карата таләпләрне билгеләүче, әлеге таләпләрне тормышка ашыру тәртибен һәм аларны бозган өчен җаваплылыкны билгеләүче норматив базаны камилләштерү буенча эш алып бару планлаштырыла. Автомобиль транспортында пассажирлар йөртү иминлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар комплексы гамәлгә ашырылачак.

Юл-транспорт һәлакәтләренең авыр нәтиҗәләрен киметү өчен, проектта авария-коткару эшләренең оперативлыгын һәм нәтиҗәлелеген арттыру чараларын гамәлгә ашыру каралган.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, аварияләрне булдырмау максатыннан, автотранспорт предприятиеләре тарафыннан өстәмә рәвештә түбәндәге чаралар эшләнде:

1. Начар климат шартларында машина йөртүчеләрнең эшенә ныклы контроль, яшь машина йөртүчеләрнең мөстәкыйль эшләвен, аларның машина йөртү күнекмәләрен тикшерүне тәэмин итүне контрольдә тоту оештырылган.

2. Юл хәрәкәте кагыйдәләре һәм машина йөртү күнекмәләре буенча йөртүчеләрнең белемнәрен өстәмә тикшерүләр үткәрелә.

3. Ял көннәрендә, төнлә һәм эштән тыш эшләрдә 3 айдан да ким эш стажы булган йөртүчеләрне эшкә җәлеп итү тыела.

4. Хәрәкәттәге составка техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау сыйфатын контрольдә тоту тәэмин ителгән.

5. Куркыныч участокларда хәрәкәт режимнарын үтәүне контрольдә тоту көчәйтелде.

6. Хәрәкәт иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча машина йөртүчеләр-остазлар белән инструктив-методик киңәшмәләр, семинарлар үткәрелә.

7. Барлык юл-транспорт һәлакәтләре дә тикшерелә.

Һәр предприятиедә күчмә составны ремонтлау, линиягә чыгарганда һәм предприятиегә кайтканда аның техник торышы, күчмә составны экипировкалау, машина йөртү составына яңа медицина таныклавы, рейс алды һәм рейстан соң контроль тикшерү, машина йөртүчеләрнең хезмәт һәм ял режимын үтәү өчен җавап бирүче структуралар бар. Кышкы һәм җәйге эш шартларына күчкәндә сезонлы инструктажлар үткәрелә. Машина йөртүчеләр составына юл-транспорт һәлакәтләренең барлык очраклары һәм сәбәпләре дә хәбәр ителә.

<u>2 проект. Юл хәрәкәтендә катнашучылар белән эшләүдә дәүләт сәясәтен камилләштерү</u>

2022-2024 елларга каралган «Юл хәрәкәте иминлеген арттыру буенча чараларга иҗтимагый ярдәм оештыру» проектындагы күп кенә чараларны «Юл хәрәкәтендә катнашучылар белән эшләүдә дәүләт сәясәтен камилләштерү» проектының икенче этабында дәвам итү күздә тотыла. Максатчан мәгълүмати-пропаганда кампанияләре ярдәмендә юл хәрәкәте иминлеге проблемасы буенча җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру, халыкны укытуның нәтиҗәле методларын кертү буенча эш дәвам итәчәк, шул исәптән балалар һәм яшүсмерләр белән юлларда куркынычсызлык кагыйдәләренә өйрәтү буенча эш көчәйтеләчәк. Машина йөртүчеләрнең һөнәри ышанычлылыгын арттыру буенча чаралар каралган. Аларның төп өлешләре булып машина йөртүчеләрне әзерләү системасын камилләштерү, юл хәрәкәте кагыйдәләрен системалы рәвештә бозучы машина йөртүчеләр белән профилактик эш алып бару, йөртүчеләргә психофизиологик диагностика үткәрү нигезләрен булдыру тора.

Проектның төп максаты – юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркыныч тәртибен кисәтү һәм транспорт чараларын йөртүчеләрнең һөнәри ышанычлылыгын арттыру.

Проект кысаларында массакүләм мәгълүмат чараларын файдаланып, юл хәрәкәтендә катнашучыларның куркынычсыз тәртибен формалаштыруга, табибка кадәр беренче ярдәм күрсәтү методларына һәм юл хәрәкәтенең хокукый мәсьәләләренә

юнәлдерелгән чаралар комплексын, массакүләм мәгълүмат чараларында юл хәрәкәте иминлеген оештыру һәм тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими мәкаләләр циклын, юл хәрәкәте иминлеге торышын аңлату һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча күрелә торган чаралар турында белгечләр чыгышлары күздә тотыла.

Массакүләм мәгълүмат чаралары ярдәмендә җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру һәм юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәү буенча махсус пропаганда кампанияләрен оештыру һәм үткәрү күздә тотыла. Бу кампанияләр контроль-күзәтчелек органнары эшчәнлеге белән яраштырылырга һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен тотышын максатчан контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга тиеш.

Әлеге чараларны тормышка ашыру халыкның игътибарын юл хәрәкәте иминлеге проблемасына җәлеп итүне, үткәрелә торган чараларга иҗтимагый ярдәм күрсәтүне һәм юл хәрәкәтендә катнашучыларда куркынычсызлык стандартларын формалаштыруны тәэмин итәргә тиеш.

Проектта юл хәрәкәтендә аеруча якланмаган катнашучыларга, балаларга, яшүсмерләргә, шулай ук пенсионерларга аерым игътибар бирелә. Балаларны һәм яшүсмерләрне транспорт культурасына өйрәтүнең һәм тәрбияләүнең юлларда һәм урамнарда үз-үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен һәм белемнәрен актив, иҗади яктан үзләштерүне тәэмин итә торган яңа, нәтиҗәлерәк формаларын һәм ысулларын кертү каралган: юл хәрәкәте иминлеге буенча иң яхшы рәсем һәм плакат конкурсы үткәрү, автотранспорт профилендәге спорт клубларын, урта белем бирү мәктәпләре каршындагы велошәһәрчекләр төзү каралган.

Проектта каралган мөһим юнәлешләрнең берсе булып юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган машина йөртүчеләр белән профилактик эш алып бару тора.

Исерек хәлдә ясалган юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү өчен машина йөртүчеләргә рейс алды тикшерүе үткәрергә кирәк. Көтелгән нәтиҗә – исерек хәлдә ясалган юл-транспорт һәлакәтләренең кимүе.

Юл-транспорт һәлакәте урынында беренче булып ЮХИДИ бүлеге хезмәткәрләре һәм автотранспорт йөртүчеләре була. Зыян күргәннәргә беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен ЮХИДИ бүлеге хезмәткәрләре, шулай ук машина йөртүчеләр беренче ярдәм күрсәтүнең билгеле бер күнекмәләренә ия булырга тиеш. Беренче медицина ярдәме күрсәтү буенча укуларны Тукай районы үзәк хастаханәсе үткәрә, укыту программасы 16 сәгатькә исәпләнгән.

Югарыда әйтелгәннәрне исәпкә алып, проектта балаларны һәм яшүсмерләрне транспорт культурасына өйрәтүнең һәм тәрбияләүнең юлларда һәм урамнарда үз-үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен һәм белемнәрен актив, иҗади яктан үзләштерүне тәэмин итә торган яңа, нәтиҗәлерәк формаларын һәм ысулларын кертү каралган.

<u>3 проект. Юл хәрәкәтен оештыруны һәм шартларын камилләштерү</u>

Әлеге проектның төп максаты булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәте оештыруның тагын да нәтиҗәлерәк схемаларын, методларын һәм чараларын эшләү һәм куллану, юл хәрәкәте шартларын камилләштерү юлы белән юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгу куркынычын киметү тора. Куелган максатка ирешү чарасы булып юллардагы куркыныч участокларны һәм куркыныч хәрәкәт шартларын бетерү һәм кисәтү буенча чаралар комплексын тормышка ашыру тора.

«Татавтодор» ААҖнең Чаллы филиалы 395,1 км территориаль автомобиль юлына хезмәт күрсәтә. Районның гамәлдәге автомобиль юллары челтәре нигездә формалашкан. Әмма күп кенә параметрлар буенча ул автомобиль хәрәкәтенең барлык үсә баручы таләпләренә туры килми, шуңа күрә транспорт чыгымнарын бөтен яклап киметү бурычы белән беррәттән, районда гамәлдәге автомобиль юллары челтәрен камилләштерү эше дә дәвам ителергә тиеш, ул теләсә нинди хуҗалык элемтәләрен гамәлгә ашырганда уңайлыкның һәм рентабельлекнең гарантияләнгән дәрәҗәсен тәэмин итәчәк.

Анализ мәгълүматлары буенча җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары (поселок эчендәге) күчеш тибындагы өслеккә ия. Бу юллар ныклык күрсәткечләре һәм автомобиль транспорты хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча төзелеш нормаларының һәм кагыйдәләренең заманча таләпләренә конструктив туры килми.

Шулай итеп, җирлекләрдә күчмә типтагы юллар саны шактый. Барлык торак пунктлар һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре дә каты өслекле юллар белән тәэмин ителмәгән. Шуңа күрә Программа чаралары юл шартларын гомуми яхшыртуга һәм юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе участокларын бетерүгә ярдәм итә.

Гамәлдәге юлларны гомуми яхшырту аларга шундый форма бирүгә һәм юл хәрәкәте кагыйдәләре таләпләренә туры килә торган хәрәкәтне җайга салуны тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

, Юл-транспорт һәлакәтләренең, шул исәптән аеруча авыр нәтиҗәләрнең сәбәпләр структурасында машина йөртүчеләрнең аруы мөһим факторларның берсе буларак, машина йөртүчеләрнең хезмәт һәм ял режимнарын үтәүгә контрольне камилләштерүне таләп итә. Нәтиҗәле контрольне гамәлгә ашыру транспорт чараларын хәрәкәт параметрларын теркәү җайланмалары белән техник җиһазландырганда мөмкин булачак.

## 4 проект. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә контроль-күзәтчелек эшчәнлеген камилләштерү

Юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча нәтиҗәле чараларның берсе булып контроль-күзәтчелек эшчәнлеген активлаштыру тора. Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала: юл хәрәкәтендә катнашучыларның эшчәнлеген (юл хәрәкәте кагыйдәләре таләпләрен үтәү) контрольдә тоту; тимер юл аркылы чыгу урыннарын һәм юлларны, ясалма корылмаларны карап тотуны һәм линиягә чыгучы транспортның төзеклеген контрольдә тоту.

Проектның төп максаты булып хокукый, оештыру, мәгълүмати һәм техник тәэмин итүне камилләштерү юлы белән, контроль-күзәтчелек эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру хисабына аварияләрне киметү тора.

Әлеге максатны тормышка ашыру өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

- юл хәрәкәте иминлеге өлкәсендә ведомствоара компетенциягә ия контроль-күзәтчелек органнарының нәтиҗәле хезмәттәшлеге системасын булдыру.

Юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе участокларын бетерүгә һәм юл шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән Программаның беренче этабы чаралары шулай ук юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе участокларында һәм башка потенциаль куркыныч участокларда юл эшләрен башкарганда алга таба да үсеш алды, автомобиль юлларында куркынычсыз транспорт развязкасын урнаштыру каралган. Юл-транспорт һәлакәтләрен ачыклауның һәм зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтүнең мәгълүмати системасын алга таба үстерү, шулай ук госпитальгә кадәрге этапта медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү күздә тотыла;

- гамәлдәге законнарга, башка норматив хокукый актларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә кагыйдәләр, стандартлар, техник нормалар һәм башка норматив документлар эшләү, машина йөртүчеләргә транспорт чаралары белән идарә итү хокукы алу һәм укыту; пассажирлар йөрткәндә һәм йөк ташыганда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, транспорт һәм юл хуҗалыгы объектларын, продукциясен һәм хезмәтләрен мәҗбүри сертификацияләү; юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә бәйле эшчәнлекне лицензияләү;

- юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуны теркәү оператив-техник чараларны, машина йөртүчеләрне әзерләү һәм аларның торышын, транспорт чараларын эксплуатацияләү, юллар төзү һәм эксплуатацияләүне диагностикалау приборларын һәм чараларын эшләү һәм кертү.

Юлларның һәм юл корылмаларының сакланышын тәэмин итү өчен куркыныч, зур габаритлы һәм авыр йөкләр ташуны контрольдә тоту буенча нәтиҗәле чаралар

системасын эшләргә һәм юл челтәрен үлчәү контроле пунктлары белән тәэмин итәргә кирәк.

Бу өлкәдә тизйөрешле хәрәкәт режимнарына, машина йөртүчеләрнең һәм пассажирларның куркынычсызлык каешларын һәм мотошлемнарны куллануга контрольне көчәйтү, исерек яисә наркотиктан исергән хәлдә машина йөртүчеләрне ачыклау буенча бурычлар өстенлекле булып тора.

Тулаем алганда, контроль-күзәтчелек органнарының юл хәрәкәте буенча эшен камилләштерү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- хәрәкәт куркынычсызлыгы өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек системасын камилләштерү буенча норматив-хокукый һәм оештыру документларын эшләү һәм раслау;
- ЮХИДИ бердәм мәгълүмати-эзләү системасын кертү;
- автотранспорт чаралары хәрәкәтен мониторинглау һәм анализлау системасын оештыру, транспорт хәрәкәте тыгыз участокларны, концентрация урыннарын ачыклау;
- кышкы чорда юлларны карап тотуны оештыруны, контрольдә тотуны һәм техник тәэмин итүне камилләштерү;
- дәүләт техник карау станцияләре контролерларын әзерләү һәм яңадан әзерләү программасын эшләү һәм тормышка ашыру;
- социаль мәсьәләләрне хәл итү (ЮХИДИ хезмәткәрләре өчен торак төзү һәм сатып алу, ЮХИДИ ветераннарына матди ярдәм күрсәтү һ. б.)

Хезмәткәрләрнең контроль-күзәтчелек эшчәнлеге нәтиҗәлелеге аларның техник тәэмин ителеше дәрәҗәсенә бәйле.

## 5 проект. Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре

Программа чараларын тормышка ашыруның югары нәтиҗәлелегенә ирешү һәм юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү буенча эш сыйфатын арттыру өчен юл хәрәкәте иминлеге системасының бөтен эшчәнлеге юл хәрәкәтен оештыру турында иң заманча белемнәргә һәм юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү эшен камилләштерү, юл челтәрен формалаштыру, транспорт хәрәкәте иминлеге һәм башка белем өлкәләре арасында үзара бәйләнешкә нигезләнергә тиеш.

Юл хәрәкәте иминлеге буенча фәнни тикшеренүләр гамәли булып тора. Алар юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмауда яки аларның санын киметүдә нәтиҗәле булырга мөмкин, дип санала. Әгәр дә юл-транспорт һәлакәтләре мөһим социаль-икътисадый проблема дип танылмаса, фәнни тикшеренүләрне аклау кыенрак булыр иде.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, фәнни тикшеренүләрнең беренче максаты юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмау түгел, ә белем алу. Әмма бу белемнәр юл-транспорт һәлакәтләрен булдырмауда әһәмиятле булырга мөмкин. Ничек кенә булмасын, шуны ышанып әйтергә була: фәнни тикшеренүләрнең сыйфаты югарырак булган саен, аның карарлар кабул итүгә йогынтысы зуррак.

Бу өлкәдә фәнни-тикшеренү эшләренең нигезе булып, мәсәлән, түбәндәгеләр тора:

- аеруча авыр нәтиҗәләргә китергән юл-транспорт һәлакәтләренең сәбәпләрен комплексды тикшерү;
- юл-транспорт һәлакәтләренең торышы һәм проблемалары мониторингы;
- иҗтимагый фикер мониторингы;
- юл-транспорт һәлакәтләре күрсәткечләрен дәүләт исәбенә алу системасын камилләштерү буенча методик рекомендацияләр эшләү;
- юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозучы машина йөртүчеләрне яңадан әзерләү буенча укыту-программа документациясен эшләү;
- авто/транспорт чараларын йөртүчеләрен әзерләүче укытучыларның квалификациясен күтәрү буенча уку-укыту планнарын һәм программаларын эшләү;
- автотранспорт чараларын йөртүчеләрне әзерләүнең инновацион технологияләрен эшләү;

- хәзерге вакытта психологик аспектларны исәпкә алмыйча, җәмгыять эшчәнлегенең бер генә өлкәсендә дә нәтиҗәләргә ирешеп булмый.

Юл хәрәкәте өлкәсе дә искәрмә булып тормый, аның уңышы күп очракта кешегә, аның осталыгына, күнекмәләренә, психика үзенчәлекләренә һәм халәтенә бәйле. Барлык юл-транспорт һәлакәтләренең 3/4 транспорт чараларын йөртүчеләр гаебе белән, аларның табигый яки хезмәт эшчәнлеге барышында алынган психофизиологик сыйфатларына, агымдагы психик яки физик халәте бозылуга, психик эшчәнлек процессында тоткарлыкларга бәйле хаталары нәтиҗәсендә килеп чыга.

Транспортта аварияне киметүгә юнәлдерелгән иң нәтиҗәле чараларның берсе – йөртүче һөнәренә кандидатларны да, аларның эш үзенчәлекләрен билгеләгәндә (такси, автобуслар, йөк транспорты, куркыныч яки аеруча кыйммәтле йөк ташу, еракка ташу һ.б.) машина йөртүчеләрне дә психофизиологик сайлап алу. Галимнәр тарафыннан машина йөртүче өчен һөнәри яктан мөһим булган сыйфатлар ачыкланган, аларга шөгыльләнеп ирешеп булмый, компенсацияләнми һәм аларның булмавы машина йөртүче булу мөмкинлеген шик астына куя. Алдынгы автомобиль илләренең транспорт психологлары бәяләвенчә, психофизиологик сайлап алуны кертү юл-транспорт һәлакәтләре санын 20%ка киметергә мөмкин.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, гамәлдәге кадрлар агентлыклары инде хәзер үк персоналны, шул исәптән машина йөртүчеләрне сайлау буенча хезмәт тәкъдим итә. Шул ук вакытта алар психологик портрет төзү белән генә чикләнәләр, бу машина йөртүчеләр өчен җитәрлек түгел, чөнки безне, барыннан да элек, аның командада нинди булуы түгел, ә юл-транспорт һәлакәтенә эләгү ешлыгы кызыксындыра.

Эшкә урнашканда психодиагностика кертү шулай ук уңай фактор булып тора, ул машина йөртүчеләрнең җаваплылыгын һәм дисциплинасын арттыра, кадрлар агымын киметә, бу юл-транспорт һәлакәтләрендә чагылыш тапмый калмый.

## 4. ПРОГРАММАНЫ ФИНАНСЛАУ

Программаны финанслауның гомуми күләме 500 мең сум тәшкил итә.

Муниципаль бюджетлардан финанслар белән идарә итүче – авыл җирлеге Башлыгы, район Башлыгы.

Әлеге финанслау күләмнәре тиешле финанс елына бюджетларны формалаштырганда төгәлләштерелергә тиеш.

Моннан тыш, мөмкинлек булган саен район бюджеты акчалары, максатчан һәм ирекле иганәләр җәлеп ителәчәк.

## 5. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ МЕХАНИЗМНАРЫ

Әлеге Программа «2018-2025 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасының, «2018-2024 елларга Россия Федерациясендә юл хәрәкәте иминлеге стратегиясен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 8 гыйнварендәге 1-р номерлы күрсәтмәсенең, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 06 декабрендәге 1115-ПУ номерлы Указының, «Татарстан Республикасында юл хәрәкәте иминлеген арттыру, юл-транспорт һәлакәтләрен кыскарту һәм аларның нәтиҗәләрен киметү чараларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 18 февралендәге 159 номерлы карарының алга таба үсеше булып тора һәм һәм «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон (2023 елның 14 ноябренә үзгәрешләр белән) һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән нормалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 6. ТРАНСПОРТ ЧАРАЛАРЫ ХУҖАЛАРЫНЫҢ ГРАЖДАНЛЫК ҖАВАПЛЫЛЫГЫН ИМИНИЯТЛӘШТЕРҮ

Зыян күрүчеләр транспорт чараларыннан файдаланганда, аларның тормышына, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә китерелгән зыянны каплау хокукларын яклау максатында, күрсәтелгән федераль закон белән транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерүнең (алга таба – мәҗбүри иминиятләштерү) хокукый, икътисадый һәм оештыру нигезләре билгеләнә.

Мәҗбүри иминиятләштерүнең төп принциплары булып тора:

- күрсәтелгән федераль законда билгеләнгән чикләрдә зыян күрүчеләрнең тормышына, сәламәтлегенә яисә мөлкәтенә китерелгән зыянны каплау гарантиясе;
- транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгын иминиятләштерүнең гомуми һәм мәҗбүри булуы;
- Россия Федерациясе территориясендә күрсәтелгән Федераль закон белән билгеләнгән гражданлык җаваплылыгын иминиятләштерү бурычын үтәмәгән транспорт чараларын кулланмау, транспорт чаралары хуҗаларының юл хәрәкәте иминлеген арттыруда икътисадый кызыксынуы.

Транспорт чаралары хуҗалары элеге Федераль законда билгеләнгән шартларда, тәртиптә һәм аның нигезендә иминиятләүчеләр сыйфатында транспорт чараларыннан файдаланганда башка затларның тормышына, сәламәтлегенә яки мөлкәтенә зыян килү нәтиҗәсендә килеп чыгарга мөмкин булган гражданлык җаваплылыгын үз хисабына иминиятләштерергә тиеш.

Мәҗбүри иминият килешүе төзелә торган шартлар Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан чыгарыла торган мәҗбүри иминиятләштерү кагыйдәләрендә булган мәҗбүри иминият шартнамәсенең типлаштырылган шартларына туры килергә тиеш.

Транспорт чарасы хуҗасының Россия Федерациясе территориясендә транспорт чарасыннан файдаланганда зыян күрүчеләрнең тормышына, сәламәтлегенә яисә мөлкәтенә зыян килү аркасында барлыкка килгән йөкләмәләр буенча гражданлык җаваплылыгы куркынычы белән бәйле мөлкәт мәнфәгатьләре мәҗбүри иминият объекты булып тора.

Транспорт чаралары хуҗалары тарафыннан мәҗбүри иминиятләштерү мәҗбүри иминият шартнамәләре төзү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мәҗбүри иминият шартнамәләрендә транспорт чаралары хуҗаларының гражданлык җаваплылыгы иминиятләштерелгән транспорт чаралары күрсәтелә.

Мәҗбүри иминият килешүе буенча транспорт чарасы хуҗасының, шулай ук транспорт чарасын законлы нигездә файдаланучы башка кешенең граждан җаваплылыгы иминиятләнә.

Мәҗбүри иминият шартнамәсе төзегәндә, иминиятче иминиятләүчегә иминият полисы һәм дәүләт үрнәгендәге махсус билге тапшыра. Мәҗбүри иминиятне гамәлгә ашыруны раслаучы документ булып иминият полисы тора.

Зыян күрүчеләр таләбе буенча компенсация түләүләре гамәлгә кую документлары нигезендә һәм 2002 елның 25 апрелендәге 40-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә эшләүче иминиятчеләрнең һөнәри берләшмәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Зыян күрүчеләр һәм иминиятчеләрнең һөнәри берләшмәсе арасындагы компенсация түләүләре уңаеннан мөнәсәбәтләрдә аналогия буенча мәҗбүри иминят шартнамәсе буенча файда алучы белән иминиятләштерүче арасындаы мөнәсәбәтләр өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән кагыйдәләр кулланыла. Тиешле нигезләмәләр Федераль законда башкасы каралмаганга һәм мондый мөнәсәбәтләрнең асылыннан башкасы килеп чыкмаганга кулланыла. Шул ук вакытта күрсәтелгән компенсация түләүләре иминиятче һәм (яки) зыян өчен җаваплы зат тарафыннан китерелгән зыянны өлешчә каплауга тигез суммага кими.

Транспорт чаралары хуҗаларының иминиятләштерү буенча күрсәтелгән Федераль закон белән билгеләнгән бурычларын үтәүне контрольдә тоту милиция тарафыннан транспорт чараларын теркәү, Дәүләт техник күзәтүен оештырганда һәм юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тоту өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, шулай ук юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә норматив хокукый актларны теркәгәндә башкарыла. Транспорт чарасын йөртүченең үзе белән мәҗбүри иминият полисы булырга һәм аны тикшерү өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле милиция хезмәткәрләренә тапшырырга тиеш.

Россия Федерациясе территориясендә әлеге Федераль закон белән билгеләнгән гражданлык җаваплылыгын иминиятләү буенча йөкләмәне үтәмәгән транспорт чараларын файдалану тыела. Күрсәтелгән транспорт чараларына карата дәүләт техник каравы һәм теркәве үткәрелми.

## 7. ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ НӘТИҖӘЛЕЛЕГЕН БӘЯЛӘҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДЫЙ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге юлларында аварияләр һәм юл-транспорт һәлакәтләрендә һәлак булучылар саны кимү, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү белән идарә итү системасын, юл хәрәкәтендә катнашучылар белән эшләү буенча дәүләт сәясәтен камилләштерү, транспорт чараларының конструктив һәм эксплуатацион куркынычсызлыгын арттыру, Әҗмәкәй авыл җирлегендә юл хәрәкәтен оештыруны камилләштерү, юл челтәрендә имин хәрәкәт шартларын тәэмин итү, юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә контроль-күзәтчелек эшчәнлеген камилләштерү, юл хәрәкәтендә катнашучылар өчен оператив радиоэлемтә булдыру һәм госпитальгә кадәрге этапта юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә ярдәм күрсәтү сыйфатын күтәрү көтелә.

Күпчелек очракта алынган нәтиҗәләргә нинди дә булса дөрес теоретик нигез бирү дә шулай ук авыр. Бигрәк тә оештыру чараларының юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен тотышы моделенә йогынтысы аз өйрәнелгән. Һәм моның үрнәге булып җәяүлеләр юллары тора. Бу чара нәтҗәсендә юл-транспорт һәлакәтләре санындагы нинди дә булса үзгәрешне исбатлау авыр. Хәтта җәяүлеләр юлы саны артса да, бу җәяүлеләрнең барысы да алардан файдаланачак, ә автомобильчеләр тизлекне алар янында киметәчәк дигән сүз түгел. Мондый чаралар буенча, бәлки, юл хәрәкәтендә катнашучыларның үз-үзләрен тотышы модельләренең башка үзгәрешләре буенча булган материалларда бушлыклар бар. Шуңа күрә китерелгән аңлатмалар шактый дөрес булырга мөмкин, әмма алар мөмкин булган, ләкин документлаштырылмаган аңлатмалар турында гипотезлар гына.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1998 елның 4 декабрендәге 1441 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе автомобиль юлларының озынлыгы, техник торышы буенча Юл хәрәкәте иминлеге күрсәткечләрен дәүләти исәпкә алу кагыйдәләре нигезендә 02.02.2000 һәм 27.08.2015 еллардагы үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән юл-транспорт һәлакәтләренең торышын бәяләү буенча түбәндәге индикаторларның дәүләт исәпкә алынуы гамәлгә ашырыла:

- хәрәкәт составы туктап тору өчен мәйданчыклар, шул исәптән туклану, сәүдә, ашыгыч медицина ярдәме һәм җир катламыннан читтә урнашкан автотранспорт тукталышларының башка урыннарында ял итү һәм кыска вакытлы тукталыш өчен мәйданчыклар саны;
- тротуарлар һәм каты өслекле җәяүлеләр юллары озынлыгы;
- автобус тукталышлары саны;
- бер дәрәҗәдә тоташу һәм киселешү урыннары саны (гади җиһазландырылмаган тоташулар һәм киселешләр, өлешчә каналларга бүленгән тоташулар һәм икенче дәрәҗәле юлда юнәлдерелгән утраулар белән киселешләр, тулысынча каналларга бүленгән

киселешләр һәм ике юлда да юнәлдерелгән утраулар белән тоташулар, боҗралы киселешләр);

- төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре таләпләренә туры китереп урнаштырылган каты өслекле (капиталь, җиңеләйтелгән һәм күчеш) төп юлга чыгу һәм керү урыннары саны;

- барлык типтагы күчмә-тизлек полосалары, шул исәптән чөйсыман, параллель, бүленү полосасы белән параллель, параллель булмаган яки кәкре сызыклы полосалар саны;

- кытыршы өслекле юл катламнарының озынлыгы (макро- һәм микрокытыршылыкны тәэмин итүче сайланган гранулометрик состав белән юл катламының беренче өслеген эшкәртү);

- ныгытылган юл читләре (сул һәм уң як), шул исәптән асфальтобетон, цемент-бетон, таш материаллар белән, үләннәр чәчеп ныгытылган юл читләренең озынлыгы;

- барьер һәм парапет тибындагы коймалар озынлыгы (төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре нигезендә беренче төркем коймалары);

- сигнал баганалары саны;

- ясалма корылмаларда һәм бордюр ташларында отбойлы бруснның югары тәгәрмәче озынлыгы;

- горизонталь (юл өслегенә төшерелә торган линияләр, язулар, уклар һәм башка билгеләмәләр) һәм вертикаль (күперләр, юлүткәргечләр, парапетлар, киртәләр, бордюрлар һәм башка юл корылмалары һәм юл элементларына төшерелә торган линияләр һәм билгеләмәләр) булу;

- расланган дислокация нигезендә юл билгеләре һәм күрсәткечләр саны;

- стационар яктырту җайланмалары саны;

- төрле дәрәҗәләрдә җәяүлеләр кичүе саны;

- тимер юллар һәм хисап бирүче оешма балансында булган автомобиль юллары кисешкән урыннарда төрле дәрәҗәдә транспорт развязкалары саны;

- машина йөртүчеләрне әзерләү сыйфаты һәм башка юл хәрәкәтендә катнашучыларның юлларда үз-үзләрен тотышы культурасы;

- отвод полосасында һәм юл буе полосасында сервис объектлары саны (автозаправка станцияләре, мотельләр, кемпинглар, техник хезмәт күрсәтү станцияләре, башка сервис объектлары);

- Россия Федерациясе автомобиль юлларында юл-транспорт һәлакәтләрен исәпкә алу һәм анализлау кагыйдәләре нигезендә ачыкланган юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе участоклары саны;

- юл-транспорт һәлакәтләре концентрациясе участокларын бетерү өчен юл эшләре башкарылган участоклар саны;

- юридик һәм физик затларныкы булган трамвай һәм троллейбуслар саны;

- юлларның сыйфаты һәм аларның кулланучылар шартларына туры килүе.

Юл-транспорт һәлакәтләренең гомумиләштерелгән индикатив күрсәткечләре сыйфатында кабул ителә:

- 1 кв.м. мәйданда гомуми файдаланудагы юлларның озынлыгы, километрларда;

- асфальт-бетон өслекле юлларның гомуми файдаланудагы юлларның гомуми озынлыгына нисбәте; %ларда;

- асфальт-бетон өслекле юллар белән гомуми файдаланудагы юллар челтәренә кадәр элемтәсе булмаган торак пунктларның чагыштырма зурлыгы, процентларда,

- авыл хуҗалыгы предприятиеләренең үзәк утарлары;

- калган торак пунктлар.

Әлеге программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә көтелә:

- районда юллардагы аварияләрне киметү һәм ел саен юл-транспорт һәлакәтләренең индикатив күрсәткечләрен киметү, бу, һичшиксез, юл-транспорт һәлакәтләренең гомуми саны картинасында чагылыш табачак:

- юл-транспорт һәлакәтләре нәтиҗәсендә җәрәхәт алучылар һәм һәлак булучылар саны, нәтиҗәләрнең авырлыгы;

- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт идарәсе системасын һәм юл хәрәкәтендә катнашучылар белән эшләүдә дәүләт сәясәтен камилләштерү;

- транспорт чараларының конструктив һәм эксплуатацион иминлеген арттыру;

- шәһәрдә юл хәрәкәтен оештыруны камилләштерү;

- юлларда имин хәрәкәт шартларын тәэмин итү;

- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү өлкәсендә контроль-күзәтчелек эшчәнлеген камилләштерү;

- хәрәкәттә катнашучылар өчен оператив радиоэлемтә системасын булдыру һәм юл-транспорт һәлакәтләрендә зыян күрүчеләргә госпитальгә кадәрге этапта ярдәм күрсәтү сыйфатын күтәрү

Башка чыганаклар: банкларның максатчан кредитлары, программаны тормышка ашыруда катнашучыларның взнослары, фондлар һәм иҗтимагый оешмалар акчалары, эшмәкәрлек структуралары чаралары, иганәче чаралары һ.б.

2026-2028 елларга Әҗмәкәй авыл җирлеге буенча юл хәрәкәте иминлеген арттыру ПРОГРАММАСЫ

| № п/п | Объектларның исеме | Егәрлек | Финанслау чыганаклары<br>Җирле бюджет, мең сумда | | | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **2026** | **2027** | **2028** | |
| 1 | Бистә э эчендәге юлларны төзү, ремонтлау һәм реконструкцияләү: | - | **-** | **-** | **-** | - |
| 2. | Җирлекнең торак пунктларында тукталыш павильоннары урнаштыру | - | - | - | - | - |
| **3** | Җирлектәге гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы балалар автомобиль мәйданчыклары: | - | - | - | - | - |
| 4 | «Ясалма тигезсезлек» урнаштыру: | - | 200 | **200** | **200** | ЖБ |
| 5. | Юлларның машиналар йөрү өлешендә разметка: сатып алу буяу өчен | - | 170 | 170 | 170 | ЖБ |
| 6. | Авыл җирлегендә юл билгеләре кую | - | **130** | **130** | **130** | ЖБ |
| 7. | Металл барьер киртәләр урнаштыру | - | - | - | - | - |
| | Итого | | 500 | 500 | 500 | ЖБ |